**СОВЕТ БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
42275 Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Большой Битаман, ул.Московская, д.2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур.,2В

Тел./факс: +7(84365) 62-847, e-mail:Bbit.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**20 февраль 2024 е.** **№83**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитетыны турында Нигезләмәсен раслау турында» 2019 елның 28 июнендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, Татарстан Респбуликасының 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитетыны турында Нигезләмәсен раслау турында» 2019 елның 28 июнендәге 142 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

 3 нче бүлекнең 3.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 17, 18 нче пунктчалар белән тулыландырырга:

 «17) алкоголь, наркотик яки башка төрле токсик исерек хәлдә булган кешеләргә ярдәм күрсәтү буенча чаралар үткәрү;

 18) участок полициясе вәкаләтлесе вазифасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазифаны биләү чорына торак бина бирү.»

2. Әлеге карарны https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Олы Битаман авыл җирлеге башлыгы Ф.Ю.Закиров